# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Кургем авылында, Куныр авыл җирлеге**
**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты**

2021 елның 9 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1. Балтач районы Куныр авыл җирлеге Кургем авылында 2022 елда торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарына, I группа инвалидларга, урын өстендә авырып ятучы ялгыз пенсионерларга,80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз пенсионерларга 90 процент күләмендә ташлама билгеләнгән, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк пенсионерларга үзара салым суммасының 50 проценты күләмендә ташлама каралганнардан кала, балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым җыйнауны кертергә.

2. Алынган акчаларны җирлектәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкарырга кулланырга җибәрергә:

- Кургем авылында: Садовая урамындагы юлны ремонтлау, спорт тренажерлары сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында. pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.О.Егоров